Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге

# КАРАР

2022 елның 11 июле, № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске- Йорт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске- Йорт авылында гражданнар Җыенының 2021 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы мәсьәлә буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зур Кукмара авыл җирлеге Уставы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Зур укмра авыл җирлегендәге Иске-Йорт авылында халык җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске- Йорт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы " гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены карарына үзгәрешләр кертү белән килешәсезме?:

«Су башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру» сүзләрен «-Су башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су башняларын буяу, су башняларын ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар алу һәм урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

«РИЗА» «КАРШЫ"»

Халык җыены беркетмәсе нигезендә: Җыенда сайлау хокукына ия булучылар 132 кеше, тавыш бирүдә катнашкаң гражданнар җыенында катнашучылар саны 70 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 70 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендәге Иске-Йорт авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре-гамәлдә, дип таныргa.

2.«Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендәге Иске- Йорт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында " 2021 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә риза буласызмы?:

«Су башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру» сүзләрен «-Су башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су башняларын буяу, су башняларын ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар алу һәм урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

«РИЗА» «КАРШЫ"»

- кабул ителгән.

3. Җыенның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев